РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин ур. 15.

Тел.:8(84364)2-63-02, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:
Kukmor.Kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru

**КАРАР** **КАРАР**

2020 елның 3 апреле № 31

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү һәм күчемле милекне һәм стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту эшләрен оештыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 60, 62, 76 статьяларына, Россия Федерациясе Граждан кодексының 222 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына таянып Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү һәм күчемле милекне һәм стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта)
2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Хәйруллинга йөкләргә.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД КУКМОР КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ ★ ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ★
Исполнительный комитет города Кукмор
ИНН 1623008296
Кукмара шәһәре башкарма комитеты

**Җитәкче** **Р. Ф. Нотфуллин**

Кукмара муниципаль районы Кумара шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 3 апрелендәге 31 номерлы карарына 1 нче кушымта

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге җир кишәрлекләрендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү һәм күчемле милекне һәм стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибе турындагы

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Нигезләмә мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем өчен мөмкин булуы, шулай ук рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү һәм күчемле милекне, стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) турындагы карарларның законлылыгы принципларына нигезләнгән һәм, оештыру-хокукый формасына һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә, барлык гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш.

1.3. Әлеге Нигезләмә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, яисә дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә, муниципаль милектәге башка күчемсез милектә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү һәм күчемле милекне һәм стационар булмаган объектларны күчерү (демонтажлау) тәртибен регламентлый.

1.4. Законсыз урнаштырылган күчемле милек – Кукмара шәһәре территориясендә (күчемсез милектә) законнарда, норматив хокукый актларда каралган хокукый нигезләрдән башка һәм/ яисә җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын бозып, шул исәптән әгәр күчемсез милек булмаган вакытлыча объектны (объектларны) урнаштыру тиешле шартнамәдә каралмаган булса, шулай ук аны урнаштыру хокукы туктатылган булса, урнаштырылган күчмә (шул исәптән вакытлыча) объект.

1.5. Күчемле милек булып түбәндәге төрдәге күчемле милек санала: стационар булмаган сәүдә объектлары (вакытлы корылмалар, вакытлы конструкцияләр һәм күчмә корылмалар), контейнерлар, күчмә каралтылар һәм корылмалар, конструкцияләр, механизмнар, төзелеш материаллары, киртәләр, ачык типтагы автостоянкалар һәм башка күчемле милек:

1) павильон – капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, сәүдә залы һәм товар запасын саклау өчен бүлмәсе булган, бер яки берничә эш урынына исәпләнгән, аерым тора торган (шул исәптән кафе, шиномонтаж остаханәләре, автомойкалар, тукталыш комплекслары, стационар бәдрәфләр) стационар булмаган күпфункцияле объект;

2) киоск – сәүдә җиһазлары белән җиһазландырылган, капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, сәүдә залы һәм товарлар саклау өчен бүлмәләре булмаган, бер эш урынына исәпләнгән, аерым тора торган стационар булмаган объект;

3) телекоммуникация контейнеры – технологик җиһазларны урнаштыру өчен билгеләнгән, металл конструкцияләрдән төзелгән контейнер тибындагы вакытлыча корылма: автоном телефон станцияләре, телефон концентраторлары, телематик узеллар, мәгълүмат тапшыру узеллары, мәгълүмат пакетларын маршрутлаштыру узеллары, сөйләм мәгълүматын челтәрләр аша тапшыру узеллары;

4) металл гараж – капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, автотранспорт чарасын каплау өчен билгеләнгән стационар булмаган объект;

5) контейнер – капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, товарлар тотыру өчен билгеләнгән тулысынча яки өлешчә ябык сыешлыктан (ёмкость) гыйбарәт транспорт җиһазы (читлек, алынмалы цистерна яки шуңа охшаш җайланма),

6) койма – капиталь төзелеш объектларына карамаган һәм күчемсез милек объекты булмаган, киртәләр сыйфатында кулланыла торган металл, агач яки башка материалдан ясалган конструкция;

7) теплица – капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, яктылык үтә торган материалдан ясалган өслекле, теплица культураларын һәм үсентеләрен үстерү өчен файдаланыла торган стационар булмаган объект;

8) кладовая – капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, азык-төлек продуктларын, утын, инвентарьны һ.б. саклау өчен файдаланыла торган стационар булмаган объект;

9) сарай – капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, хуҗалык милкен саклау, йорт хайванын тоту өчен файдаланыла торган стационар булмаган объект;

10) будка – капиталь төзелеш объектларына карамый торган һәм күчемсез милек объекты булмаган, эшчеләр һәм сакчыларны һ.б. урнаштыру өчен бина буларак файдаланыла торган стационар булмаган объект

1.6. Законсыз урнаштырылган күчемсез милек – Кукмара шәһәре территориясендә (күчемсез милектә), законнарда, норматив хокукый актларда каралган хокукый нигезләрдән башка һәм/ яисә җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе шартларын бозып, законсыз урнаштырылган күчемсез милек (рөхсәтсез төзелгән каралты).

Билгеләнгән тәртиптә бирелмәгән җир кишәрлегендә яки рөхсәт ителгән куллану әлеге объектны төзүне рөхсәт итми торган җир кишәрлегендә торгызылган яки төзелгән, яисә әгәр җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану, тиешле килешүләр, рөхсәтләр алу турында таләп һәм (яки) күрсәтелгән шәһәр төзелеше һәм төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре рөхсәтсез төзелгән корылманы торгыза башлау яки төзи башлау датасына билгеләнгән һәм рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау датасына гамәлдә булса, моның өчен закон нигезендә кирәкле килешүләр, рөхсәтләр алмыйча гына яки шәһәр төзелеше һәм төзелеш нормаларын һәм кагыйдәләрен бозып торгызылган яки төзелгән бина, корылма яки башка каралты рөхсәтсез төзелгән корылма була.

1.7. Рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү, законсыз урнаштырылган күчемле милекне, стационар булмаган объектны демонтажлау (күчерү) турында мәсьәләләрне карауны Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты (текстта алга таба – Башкарма комитет) башкара.

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган корылмаларны, стационар булмаган объектларны ачыклау эшен Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмаларны ачыклау һәм демонтажлау буенча ведомствоара комиссия башкара (алга таба – Комиссия).

Комиссия эшчәнлеге әлеге Нигезләмә һәм Башкарма комитет раслаган Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмаларны, стационар булмаган объектларны ачыклау һәм демонтажлау буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмә белән регламентлана.

1.8. Рөхсәтсез төзелгән корылманы һәм (яки) законсыз урнаштырылган күчемле мөлкәтне, стационар булмаган объектны ачыклауның һәр очрагы актны төзү датасы, вакыты; объектны ачыклаган органның исеме, затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы; ачыкланган объектның урнашу урыны; ачыкланган хокук бозулар турында, әлеге хокук бозуларны кылган өчен җаваплылык йөкләнә торган затлар (әгәр андыйлар билгеләнгән булса) турында белешмәләр, таләпләре бозылган норматив хокукый актның статьялары һәм пунктлары; рөхсәтсез төзелгән объектны ачыклаганда катнашкан затларның акт белән танышу яки танышудан баш тартулары турындагы белешмәләр, аларның имзалары яки имза салудан баш тартулары һәм башка белешмәләр күрсәтелгән акт белән рәсмиләштерелә (1 нче кушымта).

Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы һәм (яки) законсыз урнаштырылган күчемсез милекне, стационар булмаган объектларны ачыклау турында акт төзегәндә, Комиссия ачыкланган стационар булмаган объектны урнаштырган затны (гражданны яки юридик затны)

ачыклау өчен чаралар күрә, һәм әлеге затны законсыз рәвештә билгеләнгән корылманы ачыклау турындагы акт белән таныштыруны тәэмин итә. Рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган зат акт белән танышудан баш тарткан очракта, анда тиешле язма ясала.

Ачыкланган рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган зат дип әлеге Нигезләмә кысаларында ачыкланган рөхсәтсез корылманы, стационар булмаган объектны урнаштырган һәм (яки) аннан файдаланган граждан яисә юридик зат аңлашыла.

Ачыкланган рөхсәтсез төзелгән корылманы, стационар булмаган объектны рөхсәтсез урнаштырган зат булмаган очракта, шулай ук ачыкланган рөхсәтсез төзелгән корылманы, стационар булмаган объектны рөхсәтсез урнаштырган затны ачыклау мөмкин булмаса, аны демонтажлау, ташу һәм саклау әлеге Нигезләмәнең 1.15 пунктында каралган тәртиптә башкарыла, бу хакта актта тиешле билге ясала.

1.9. Законсыз рәвештә рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау турында законсыз рәвештә рөхсәтсез корылма төзегән затка карата акт төзелгәннән соң, ачыкланган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау турында Комиссия әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча таләпне төзи.

Законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау турында таләп законсыз рәвештә рөхсәтсез төзелгән корылманы урнаштырган затка (гражданга яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә) шәхсән имза куйдырып тапшырыла яисә рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган затны ачыклаганда комиссия тарафыннан билгеләнгән адреска тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша җибәрелә.

Законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау турындагы таләпне рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз рәвештә урнаштырган затка (гражданга яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә) тапшыру белән бер үк вакытта таләп законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмага әйләнә-тирә мохит йогынтысына чыдам махсус чаралар белән язып урнаштырыла.

Җир кишәрлеген азат итү турындагы таләптә күрсәтелгән рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз рәвештә урнаштырган зат (граждан яки юридик зат), аңа таләпне тапшырганнан соң, ике атна эчендә үз көче белән һәм үз хисабына рөхсәтсез төзелгән законсыз рәвештә урнаштырган корылманы сүтеп алырга тиеш.

1.10. Рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз рәвештә урнаштырган граждан яки юридик зат законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау турында таләпләрне үтәмәгән очракта, Комиссия законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы Башкарма комитет көче белән демонтажлау турында Карар кабул итә.

Башкарма комитет «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Граждан кодексы белән билгеләнгән тәртиптә мөлкәтне эвакуацияләү һәм саклау буенча хезмәтләр күрсәтүгә оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.

1.11. Демонтаж датасы турында рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган затка әлеге Нигезләмәнең 1.9. пунктында каралган тәртиптә, әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә форма буенча хәбәрнамәне тапшыру (җибәрү) юлы белән Комиссия тарафыннан хәбәр ителә.

1.12. Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау комиссия әгъзалары катнашында Башкарма комитет законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау, ташу һәм саклау буенча эшләр башкаруга шартнамә яки муниципаль контракт төзегән зат (алга таба – Оешма) тарафыннан башкарыла.

Сүтеп урыныннан алу (демонтаж) һәм транспортлау ысулын сайлау җаваплылыгы оешмага йөкләнә. Оешма һәм (яки) комиссия вәкиле фикеренчә, законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау аны сүтмичә мөмкин булмаса, бу хакта законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау актында билге ясала.

Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау процедурасын теркәү өчен фото- яки видеога төшерүнең техник чаралары кулланыла.

Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы һәм анда булган мөлкәтне демонтажлау алдыннан Комиссия исәпкә алырга тиеш. Мөлкәт исемлеге Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм законсыз рәвештә урнаштырылган корылманы демонтажлау турындагы актка кушымта булып тора.

Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау турындагы Акт, законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау тәмамланганнан соң, әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендә төзелә.

Актка рөхсәтсез төзелеш урнаштырган зат (граждан яки юридик затның вәкаләтле вәкиле) кул куя. Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы сүткән вакытта ул булмаган яки имзадан баш тарткан очракта, актта тиешле язма ясала.

1.13. Демонтажланган законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылма һәм демонтажланган вакытта анда булган мөлкәт, мөлкәт исемлеге нигезендә, әлеге мөлкәтне саклау тәэмин итәлә торган демонтажланган стационар булмаган объектларны туплау урынына чыгарылырга тиеш.

Башкарма комитет һәм Оешма, реализация срогы чыгу сәбәпле ташу һәм саклау вакыты дәвамында яраксызга чыккан яисә саклау шартлары бозылу яки демонтажга кадәр яраксызга чыккан товарлар өчен җаваплылык тотмыйлар.

1.14. Демонтажланган законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылма һәм демонтажланган вакытта анда булган мөлкәт, мөлкәт исемлеге нигезендә, стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган затка, законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектны демонтажлау чараларына бәйле чыгымнарны Башкарма комитетка кайтарганнан соң, кире кайтарылырга тиеш.

Башкарма комитетның әлеге пунктта күрсәтелгән чыгымнары сүтелергә, демонтажланырга тиешле рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган зат тарафыннан ирекле яки суд тәртибендә тулысынча кире кайтарылырга тиеш.

1.15. Рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз рәвештә урнаштырган затны ачыклау мөмкинлеге булмаган очракта, Башкарма комитет Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Хезмәт даны» район газетасында законсыз рәвештә урнаштырган рөхсәтсез төзелгән корылманы хәбәр басылганнан соң ике атна эчендә ирекле рәвештә демонтажлау һәм җир кишәрлеген азат итү турындагы тәкъдим белән мәгълүмати хәбәр урнаштыруны тәэмин итә.

Мәгълүмати хәбәр урнаштыру белән бер үк вакытта Комиссия тарафыннан законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылмага, законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы язма урнаштырылганнан соң ике атна эчендә ирекле демонтажлау һәм җир кишәрлеген азат итү турында таләп куеп, әйләнә-тирә мохит йогынтысына чыдам махсус чаралар белән язма урнаштырыла, шулай ук рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган затны билгеләүдә ярдәм итүләрен сорау максатында хокук саклау органнарына запрос җибәрелә.

Әгәр, Комиссия тарафыннан законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау турында акт төзелгәннән 14 көн үткәннән соң, рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз рәвештә урнаштыручы зат ачыкланмаган булса, Комиссия законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында Карар кабул итә.

Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау әлеге Тәртипнең 1.12. пунктында каралган тәртиптә башкарыла.

Законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау, аны саклау урыны һәм вакыты турында мәгълүмат Башкарма комитет тарафыннан «Хезмәт даны» район газетасында басылып чыга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Демонтажланган законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылма һәм демонтажлаган вакытта анда булган мөлкәт, мөлкәт исемлеге нигезендә, стационар булмаган объектны законсыз рәвештә урнаштырган зат гаризасы буенча, Башкарма комитетка чыгымнарны әлеге Тәртипнең 1.14 пунктында каралган тәртиптә түләп бетергәч, кире кайтарылырга тиеш.

1.16. Алынмый калган демонтажланган законсыз урнаштырылган стационар булмаган объект һәм демонтажлаган вакытта анда булган мөлкәт, мөлкәт исемлеге нигезендә, Башкарма комитет белән килешү буенча өч ай дәвамында сакланырга тиеш.

Әгәр өч ай узгач, демонтажланган законсыз урнаштырылган стационар булмаган объект хуҗасы ачыкланмаган булса, Башкарма комитет стационар булмаган объектка ия була һәм стационар булмаган объектны хуҗасыз дип тану һәм аны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә утильләштерү өчен муниципаль милеккә тапшыру турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.

Суд карары стационар булмаган объектның бәясе биш тапкыр минималь хезмәт хакы күләменә туры килә торган суммадан түбәнрәк булган очракта таләп ителми.

## 2. Демонтажланган законсыз урнаштырылган күчмә объектларны һәм матди кыйммәтләрне саклау, транспортлау һәм утильләштерү

2.1. Вакытлыча саклау урыннарына сакларга тапшырылган рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объектлар һәм башка мөлкәт хуҗасына милек һәм объектларга хокукны раслаучы документларны, шулай ук әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү, законсыз урнаштырылган объектны һәм демонтажланган объектта табылган мөлкәтне күчерү (демонтажлау) һәм саклау, шулай ук әлеге мөлкәтне калдыклар сыйфатында транспортлау һәм утильләштерү буенча чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны кайтаруны раслый торган документларны тапшырганнан соң бирелә.

Хуҗасы мөрәҗәгать иткән көнне, әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тикшергәннән соң, саклау өчен җаваплы зат хуҗага вакытлыча саклау урыныннан рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объектларны һәм башка мөлкәтне бирү мөмкинлеген килештерү турында тамга белән тапшыру-кабул итү актын бирә.

Тапшыру-кабул итү акты саклау өчен җаваплы зат тарафыннан, рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объектны һәм башка мөлкәтне тапшырганда рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объект хуҗасы тарафыннан һәм Башкарма комитетның вазыйфаи заты тарафыннан имзалана. Актның бер нөсхәсе – рөхсәтсез (законсыз) объект хуҗасында, икенчесе – саклау өчен җаваплы затта, өченчесе – Башкарма комитетта кала.

2.2. Демонтаждан соң саклауда булган объектны һәм башка мөлкәтне алу өчен, объект хуҗасы саклауны башкаручы затка язма гариза белән мөрәҗәгать итә, аңа түбәндәге документлар теркәлә:

2.2.1. Рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү, законсыз урнаштырылган объектны һәм объектта табылган мөлкәтне демонтажлау, күчерү һәм саклау, шулай ук әлеге мөлкәтне калдыклар сыйфатында транспортлау һәм утильләштерү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны түләүне раслаучы түләү документы күчермәсе.

2.2.2. Объектларга һәм милеккә хокукны раслаучы документлар (сату-алу, бүләк итү, аренда шартнамәләре һәм башка документлар) һәм объектка милек хокукын раслаучы һәм анда булган мөлкәткә хокукны раслаучы башка документлар күчермәләре.

2.3. (Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар суммасы) рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объект хуҗасы тарафыннан Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелә.

Законсыз урнаштырылган объектларны сүтү, демонтажлау, күчерү, саклау, транспортлау һәм утильләштерү, шулай ук рөхсәтсез төзелгән һәм законсыз урнаштырылган күчмә объектларда табылган мөлкәтне саклау, транспортлау һәм утильләштерү юридик яки физик зат тарафыннан хезмәт күрсәтү турындагы килешү нигезендә түләүсез гамәлгә ашырылган очракта, рөхсәтсез (законсыз) объектның законлы хуҗасы тарафыннан чыгымнарны каплау әлеге чараларны гамәлгә ашыручы затка башкарыла.

Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау күләме, факттагы саклау вакытына карап, чыгымнарның факттагы суммасыннан чыгып исәпләнә.

2.4. Әгәр хуҗасы вакытлыча саклау урынында булган мөлкәтне сорап бер ел дәвамында мөрәҗәгать итмәсә, мөлкәт Россия Федерациясе Граждан кодексы белән каралган тәртиптә

муниципаль милеккә әверелергә, һәм аннан соң рөхсәтсез төзелгән объектларны сүтү, мөлкәтне күчерү һәм аны саклау белән бәйле чыгымнарны кайтару максатында гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырылырга мөмкин.

## 3. РӨХСӘТСЕЗ ТӨЗЕЛГӘН КОРЫЛМАЛАРНЫ СҮТҮ, ЗАКОНСЫЗ УРНАШТЫРЫЛГАН КҮЧМӘ ОБЪЕКТЛАРНЫ ҺӘМ АНДА ТАБЫЛГАН МӨЛКӘТНЕ КҮЧЕРҮ (ДЕМОНТАЖЛАУ), САКЛАУ, ТРАНСПОРТЛАУ ЯКИ УТИЛЬЛӘШТЕРҮ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЧЫГЫМНАР

3.1. Рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объектларны демонтажлау, күчерү, саклау, демонтажланган объектларда табылган ташландык һәм мөлкәт буларак аларны транспортлау һәм күмү яки утильләштерү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү әлеге чараларны гамәлгә ашыручы затлар исәбеннән тормышка ашырыла, алга таба рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объект хуҗасы чыгымнарны каплый.

3.2. Әгәр «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль контракт һәм Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә шартнамә төзелгән юридик яки физик зат тарафыннан рөхсәтсез төзелгән (законсыз) объектларны демонтажлау, күчерү, саклау, демонтажланган объектларда табылган ташландык һәм мөлкәт буларак аларны транспортлау һәм күмү яки утильләштерү түләүле нигездә башкарылса, чыгымнарны исәпләү Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз рәвештә урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау һәм демонтажлау Тәртибенә 1 нче кушымта

АКТ № _______

"__" ________ 20___ ел Кукмара шәһәре

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау турында

Комиссия түбәндәге составта

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(ФИО, комиссия әгъзалары вазыйфасы)

әлеге актны түбәндәгеләр турыда төзеде

______________________________________________________________________________

(стационар булмаган объектның адресы һәм урнашу урыны)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган зат мәгълүматлары: ФИО һәм адресы – граждан өчен; вәкаләтле вәкилнең атамасы, адресы, ФИО һәм вазыйфасы – юридик затлар өчен)

билгеләнгән ______________________________________________________________,

(рөхсәтсез төзелгән корылманың исеме)

нәрсәдән ясалган __________________________________________________________

Әлеге җир кишәрлеге стационар булмаган объектны урнаштыру өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелмәгән.

Акт белән таныштым _______________________________________________________

(гражданның яисә рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган юридик затның вәкаләтле вәкиленең ФИО, вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе:___________________________________________________________

(имза)

Комиссия әгъзалары:______ _________________________________________________

(имза)

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау һәм демонтажлау Тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау турында таләп

"__" ________ 20___ ел                                   Кукмара шәһәре

Бирелде_______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган зат мәгълүматлары: ФИО гражданин өчен; атамасы, адресы – юридик зат өчен)

рөхсәтсез урнаштырылган стационар булмаган объектка карата

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(законсыз урнаштырылган объектның исеме)

урнашкан адресы:______________________________________________________________

Комиссия составы:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(ФИО, комиссия әгъзалары вазыйфасы)

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектны ачыклау турында акт төзелде

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(дата һәм актның номеры)

20__ елның "____" ______________ кадәр үзегезнең көчегез һәм акчаларыгыз белән Сезнең тарафтан законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы (төзелешнең исеме) демонтажларга тәкъдим итәбез.

Комиссия карары буенча объект 10 календарь көн дәвамында мәҗбүри тәртиптә демонтажланачак һәм урыныннан алыначак. Законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау, ташу һәм саклау буенча барлык чыгымнар сездән РФ законнарында каралган тәртиптә түләттереләчәк.

Әлеге таләпнең үтәлеше турында Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетына 20__ елның «__» ____________ кадәр хәбәр итүегезне сорыйбыз.

Таләп алынды ___________________________________________________________

(Стационар булмаган объектны рөхсәтсез урнаштырган гражданның яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең ФИО, вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе: ________________________________________________________

(имза)

Комиссия әгъзалары:          ___________________________________________

(имза)

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау һәм демонтажлау Тәртибенә 3 нче кушымта

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез корылманы демонтажлау датасы турында ____ номерлы хәбәрнамә

Комиссия түбәндәге составта

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(комиссия әгъзалары ФИО, вазыйфасы)

хәбәр итә ______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган зат мәгълүматлары: ФИО һәм адресы – граждан өчен, атамасы, адресы, ФИО һәм вәкаләтле затның вазыйфасы – юридик зат өчен)

законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектны демонтажлау

______________________________________________________________________________

(объектның адресы һәм атамасы)

Кукмара муниципаль районы Кумара шәһәре Башкарма комитеты көче белән узачак

______________________________________________________________________________

(дата һәм Мәскәү вакыты)

Хәбәрнамә алынды ______________________________________________________________

(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган граждан яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленең ФИО, вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе: ________________________________________________________________

(имза)

Комиссия әгъзалары: ____________________________________________________________

(имза)

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз үзбелдекле урнаштырылган корылманы ачыклау һәм демонтажлау Тәртибенә 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау
Акты № ______

"__" ________ 20___ ел                                        Кукмара шәһәре

Түбәндәге составта Комиссия
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(комиссия әгъзалары ФИО, вазыйфасы)
һәм __________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган граждан яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле ФИО, вазыйфасы, имзасы)
законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы мәҗбүри демонтажлау үткәрелде
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(төзелеш атамасы)
Нәрсәдән ясалган _____________________________________________________________
______________________________________________________________________________
урнашкан адресы:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
Законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылма сүтеп алынды
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(объектны демонтажлаган юридик затның ФИО яки атамасы)

Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы ачыклау турында ________ елның ______ ________________ _____ номерлы акт, җир кишәрлеген азат итү турында________ елның ______ ________________ _____ номерлы таләп һәм законсыз урнаштырылган рөхсәтсез төзелгән корылманы демонтажлау турында ________ елның ______ ________________ ____ номерлы комиссия карары нигезендә
Демонтаж вакытына объектның тышкы хәле:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
Объектны ачу эшләре башкарылмады (башкарылды).
Объектны сүтү эшләре башкарылмады (башкарылды).
Мәҗбүри демонтажланган стационар булмаган объект урнаштырылган:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(адресы)
һәм җаваплы саклауга тапшырылган
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

(исеме, ФИО, вазыйфасы)

Актка кушымта: стационар булмаган объект һәм аны демонтажлаган вакытка законсыз урнаштырылган стационар булмаган объектта булган мөлкәт исемлеге.

Әлеге акт 3 нөсхәдә төзелде һәм тапшырылды (җибәрелде):
- Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетына;
- рөхсәтсез төзелгән корылманы законсыз урнаштырган затка (гражданга яисә юридик затка)
________________________________________________________________________
(объектны саклауга кабул иткән затның исеме)

Акт белән таныштым ___________________________________________________
_______________________________________________________________________
(стационар булмаган объектны законсыз урнаштырган граждан яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле ФИО, вазыйфасы, имзасы)

Комиссия рәисе: ___________________________________________________
(имза)

Комиссия әгъзалары: _________________________________________________
(имза)

Объектны саклауга кабул иткән зат: _______________________________________
(имза)